МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.09.2023 Казан ш № 720

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 июнендәге 627 номерлы, 2022 елның 7 ноябрендәге 989 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 5 сентябреннән 720 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү турында» 2023 елның 24 июнендәге 1026 номерлы карары белән расланган Соңгы эш урыны (хезмәт урыны) буенча уртача хезмәт хакын исәпләү кагыйдәләренең 5 пунктында каралган очракларда, теркәлгән гражданин шәхсән үзе соңгы эш урыны (хезмәт урыны) буенча эш бирүче тарафыннан исәпләнгән уртача хезмәт хакы турында белешмәне Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча тапшыра.»;

2.6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

паспортның хакыйкыйлыгы турында мәгълүмат – Россия Эчке эшләр министрлыгы (ведомство мәгълүмат системасы);

яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр – Россия ЭЭМ (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт эшчәнлеге турында, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны турында белешмәләр – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» (ведомство мәгълүмат системасы);

иминият стажы турында мәгълүмат – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» (ведомство мәгълүмат системасы);

соңгы эш (хезмәт) урыны буенча түләүләр турында һәм башка бүләкләү турында белешмәләр, шул исәптән мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенә иминият кертемнәре кучерелгән белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

белеме, квалификациясе турында белешмәләр – Рособрнадзор («Белем турында һәм (яки) квалификация, белем алу турында документлар турында мәгълүматларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

лаеклы ял алды яшендәге гражданнарга кертелү турында белешмәләр – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар – Россия ФСХ (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Россия ФСХ (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры);

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында белешмәләр – Россия ФСХ (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусы турында мәгълүмат – Россия ФСХ («Һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусын тикшерү» гавами сервисы;

адвокат статусы турында белешмәләр – Россия Юстиция министрлыгы (Россия Федерациясе субъектларының адвокатлар реестры);

нотариус вәкаләтләре һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар турында белешмәләр – Россия Юстиция министрлыгы (нотариуслар һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар реестры);

бала туу турында белешмәләр (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия ФСХ (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

гражданинның үлеме турында белешмәләр – Россия ФСХ (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

пенсия алу факты турында белешмәләр – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» (ведомство мәгълүмат системасы);

гражданнарны ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә кертү турында мәгълүмат (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы);

вакытлыча эшкә яраксызлык чоры турында мәгълүмат – «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» (ведомство мәгълүмат системасы)»;

2.7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинның тиешле эш эзләү максатыннан теркәлү өчен дөрес булмаган мәгълүматны тәкъдим итүе. Гаризаны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр гражданинга гражданин биргән дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланганнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.»;

2.8.5 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) гражданинны «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясында каралган нигезләр буенча мәшгуль дип тану;»;

2.14.1 пунктында «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;
2.14.3 пунктында «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;
2.14.5 пунктында «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;
3 бүлектә:

3.3.4.4 пунктның өченче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр нигезендә саналган» сүзләрен «Уртача хезмәт хакын исәпләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 24 июнендәге 1026 номерлы карары белән расланган тәртиптә саналган» сүзләре белән, «хезмәт» сүзен «иминият» сүзе белән алмаштырырга;

3.4.1 пунктта:

дүртенче абзацта «факты» сүзен «урыны» сүзе белән алыштырырга;

бишенче абзацта «хезмәт» сүзен «иминият» сүзе белән алыштырырга;

алтынчы абзацта «(хезмәт)» сүзеннән «шул исәптән» сүзләре белән тулыландырырга;

3.5.2 пунктның бишенче абзацында «2021 елның 14 сентябрендәге 1552 номерлы» сүзләрен «2023 елның 24 июнендәге 1026 номерлы» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.7 пунктның дүртенче абзацында «туры килә торган эшнең сайланган ике вариантыннан» сүзләрен «Гражданнарны теркәү кагыйдәләренең 24 һәм 26 пунктларына ярашлы рәвештә туры килә торган эш тәкъдимнәре исемлегеннән сайланган тиешле эшнең ике вариантыннан» сүзләр белән алыштырырга;

3.5.9 пунктында:

уналтынчы абзацта «мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме беренче абзацта «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;

3.6.1 пунктның 2 пунктчасында «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;

3.6.3 пунктының дүртенче абзацында «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;

3.7 пунктта:

унберенче абзацта «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;

уникенче абзацта «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;

ундүртенче абзацта «вариантлар» сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга;

Регламентның 2 нче кушымтасында «вариантлар» сүзен сүзен «тәкъдимнәр» сүзе белән алыштырырга.